СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**
**21.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 478**

«Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 ел» юбилей медален гамәлгә кую турында

Казан губернасы Зөя өязе, хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Зеленодольск районы Югары Шырдан авылында туган бөек татар галиме-этнографы, әдәбиятчысы һәм мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның 2025 елда ике йөз еллык юбилеен бәйрәм итүгә бәйле, Зеленодольск муниципаль районы Советы карар карар кылды:

1. «Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 ел» юбилей медален гамәлгә куярга.
2. «Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 ел» юбилей медален гамәлгә кую турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми (htpp:/pravotatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы Советының
2025 елның 21 мартындагы
478 номерлы карарына
кушымта

«Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 ел» юбилей медален
гамәлгә кую турында нигезләмә

1.1. Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 еллык уңаеннан юбилей медале (алга таба-юбилей медале) белән мәдәният, мәгариф өлкәсендә эшләүчеләр, фәнни оешмалар хезмәткәрләре, дәүләт граждан хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары, шулай ук оештыру-методик, фәнни-гамәли һәм идарә эшчәнлегенә зур өлеш керткән башка затлар (алга таба - кандидатлар) бүләкләнә.

1.2. Юбилей медале бүләкләнүчегә социаль һәм башка ташламалар яисә өстенлекләр бирү өчен нигез булып тормый.

1.3. Кандидатларның үтенечнамәләрен һәм документларын Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан төзелгән һәм расланган Бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау буенча комиссия (алга таба – Комиссия) карый.

## II. МЕДАЛЬ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ ТӘРТИБЕ

2.1. Юбилей медале белән бүләкләү әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла.

2.2. Юбилей медале белән бүләкләү турында үтенечнамә белән оешмалар, учреждениеләр, иҗтимагый берләшмәләр, җирле үзидарә органнары яклап чыга.

Гражданнарның шәхси мөрәҗәгатьләре буенча бүләкләү башкарылмый.

2.3. Юбилей медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы исеменә Юбилей медале белән бүләкләүгә дәгъва кылучы гражданның конкрет казанышларын тасвирлап җибәрелә.

2.4. Комиссия үтенечнамәне тапшырган көннән алып бер ай эчендә карый. Юбилей медале белән бүләкләү турындагы үтенечнамә кире кагылган очракта, Комиссия карар кабул иткән көннән алып бер ай эчендә, Комиссия мондый карарның мотивларын үтенечнамә инициаторына хәбәр итә.

2.5. Медальләргә заказ бирү һәм аларны исәпкә алу Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге тарафыннан алып барыла.

## III. МЕДАЛЬ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮНЕ РӘСМИЛӘШТЕРҮ ТӘРТИБЕ

3.1. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге Комиссия утырышына документлар әзерли.

3.2. Тапшырылган документлар һәм Комиссия бәяләмәсе нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан Юбилей медале белән бүләкләү турында карар кабул ителә.

3.3. Юбилей медале белән бүләкләү турындагы карар Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында игълан ителә.

3.4. Бүләкләнгән затка юбилей медале һәм билгеләнгән үрнәктәге таныклык тапшырыла.

3.5. Юбилей медален һәм таныклыкны тантаналы шартларда Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тапшыра.

3.6. Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы йөкләмәсе буенча һәм аның исеменнән юбилей медален түбәндәгеләр тапшырырга мөмкин:

- Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы урынбасары;

- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарлары;

- Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе;

- Зеленодольск муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең башлыклары, җитәкчеләре, җитәкче урынбасарлары, башкарма комитет секретарьлары.

3.7. Исән вакытында юбилей медале тапшырылмаган бүләкләнүче вафат булган очракта, бүләк аның гаиләсенә саклау өчен тапшырыла.

3.8. Юбилей медален югалткан очракта аның дубликаты бирелми.

3.8. Кабат юбилей медале белән бүләкләү рөхсәт ителми.

3.9. Бүләкләнүчеләрне исәпкә алуны Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлеге башкара.

## IV. БҮЛӘКЛӘҮ ТУРЫНДАГЫ КАРАРЛАРНЫ ГАМӘЛДӘН ЧЫГАРУ, МЕДАЛЬДӘН МӘХРҮМ ИТҮ

4.1. Бүләкләгәннән соң медаль белән бүләкләнүнең дөрес булмавы яки нигезсезлеге ачыкланса, Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы Юбилей медале белән бүләкләү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга хокуклы.

4.2. Юбилей медале белән бүләкләүне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән затка тапшырылган юбилей медале Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар сәясәте бүлегенә кире кайтарылырга тиеш.

## V. «МӘГЪРИФӘТЧЕ-ГАЛИМ КАЮМ НАСЫЙРИ ТУУЫНА 200 ЕЛ» ЮБИЛЕЙ МЕДАЛЕ СУРӘТЕ ҺӘМ ТАСВИРЛАМАСЫ.

5.1. «Мәгърифәтче -галим Каюм Насыйри тууына 200 ел» юбилей медаленең сурәте һәм тасвирламасы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан әзерләнә һәм Комиссиягә тапшырыла.

5.2. Комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тәкъдим иткән юбилей медалендәге сурәтләрне һәм тасвирламаны карый һәм килештерә.

5.3. Юбилей медаленең сурәте һәм тасвирламасы Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы тарафыннан раслана.